**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«03» октября 2022 ел №409

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Олы Шилнә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Кече Шилнә» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 30 октябренә 10.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Олы Шилнә авылында Победа урамы буенча 21 йорт янында Олы Шилнә авылының Победы ур., Кутузова ур., Багратиона ур., Крайняя ур., Суворова ур., Р.Маленовского ур., С.Буденого ур., С.Бирюзова ур., И.Баграмяна ур., М.Тухачевского ур., А.Егорова ур., К.Ворошилова ур. буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

2. 2022 елның 30 октябренә 11.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Олы Шилнә авылында Нефтянников урамы буенча ,50 йорт янында Олы Шилнә авылының Юбилейная ур., Нефтянников, Королева ур, Березовая ур., Татарстан ур., Рябиновая ур., В.Филинова ур., Овражная ур, Шоссейная ур, Восточная ур, Ключевая ур., Весенняя ур., Снежная ур., Кедровая ур., Жукова ур., Новошильнинская ур., Полевая ур., Луговая ур., Солнечная ур., Казанская ур., Г.Тукая ур., Спартаковская ур., Г.Богомолова ур., Пушкина ур., Ак.Королева ур, Б. Мансурова, 100 лет ТАССР.

3. 2022 елның 30 октябренә 12.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Олы Шилнә авылында Кирова урамы буенча 55 йорт янында Олы Шилнә авылының Титова ур., Кирова ур., Придорожная ур., Первый переулок Титова ур., Боровецкая р., Животноводов ур., Дачная ур., Вишневая ур, Чулпан ур., Камская ур, Речная ур., Прибрежная ур., Зарековка ур., Снежная ур., Весенняя ур., Ключевая ур., Мостовая ур., Титова пер., Титова оченче пер., буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

4. 2022 елның 30 октябренә 13.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Олы Шилнә авылында Орхидейная урамы буенча 2 йорт янында Олы Шилнә авылының Орхидейная ур., Виноградная ур., Надежды ур., Васильковая ур., Отрадная ур., Алмазная ур., Торжественная ур., Ракитовая ур., Сиреневая ур., Молодости ур., Лазурная ур., Веселая ур., Летняя ур., Севастопольская ур., Гаяза Исхаки ур., Южная ур., 70 лет Победы ур., Кукморская ур., Самаркандская ур., Камская аллея ур., буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен Олы Шилнә авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләне расларга:

««2023 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге Олы Шилнә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 2000 (ике мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Олы Шилнә авылында юлларны ремонтлау;
2) балалар-спорт һәм җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү;
3) урам утларын урнаштыру һәм ремонтлау
4) тротуарны төзекләндерү
5) су челтәрләрен ремонтлау (ремонт эшләре, проект эшләре)

«ӘЙЕ» «ЮК».

7. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

9. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы А.Г. Даутов